Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
К А Р А Р Ы

7 февраль 2013 ел № 273

Татарстан Республикасында дәүләт
вәкаләтләрен гамәлгә кую, хайван
авыруларын кисәтү, аларны ликвидацияләү,
дәвалау, кешеләр һәм хайваннарны әлеге
авырулардан саклауны оештыруны билгеләүче
вәкаләтле орган турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә эшчәнлеген оештыру принциплары" турында 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль Закон, "Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарын һәм "Яр Чаллы шәһәре" шәһәр округын Татарстан Республикасында дәүләт вәкаләтен гамәлгә кую, хайван авыруларын кисәтү, аларны ликвидацияләү, дәвалау, кешеләр һәм хайваннарны әлеге авырулардан саклау" турындагы 2013 елның 12 гыйнварендагы №9–ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетын Татарстан Республикасында дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә кую, хайван авыруларын кисәтү, аларны ликвидацияләү, дәвалау, кешеләр һәм хайваннарны әлеге авырулардан саклауны оештыруны билгеләүче вәкаләтле орган итеп билгеләргә:

-гамәлдәге закон нигезендә, себер язвасы белән авыручы хайваннар күмелгән каберлекләрне һәм биотермик чокырларны (алга таба объект) карап тору, тирә–ягын төзекләндерү, тиешле санитар нормада тоту;

-объектта куркынычсызлык чараларын булдыру;

-биотермик чокырларны консервацияләү.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетына дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыручы махсус урындагы затлар билгеләргә.

3.Әлеге карарны "Знамя труда", "Әлмәт таңнары" газеталарында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлмәт муниципаль районы Советының аграр мәсьәләләр, табигый ресурслар һәм экологик куркынычсызлык (Р.А.Нугайбеков), Әлмәт муниципаль районы Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә (Р.Н.Мөхәммәдиев) йөкләргә.

Әлмәт муниципаль районы башлыгы М.Х.Салихов